ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Советская, д.1а, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

Совет ур., 1 нче а йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

от 11 ноября 2022 г. — № 13

**Уразбахты авыл җирлеге Башкарма комитетының «Салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында" гы 30.04.2021 ел, № 7 карарына үзгәрешләр кертү турында**

« Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитетының 30.04.2021 ел, № 7 карары белән расланган салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 пункттан һәм 12 пунктның 2 абзацыннан «муниципаль программаларның структур элементлары»сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 2 пункттан «муниципаль программаларның структур элементлары»сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3. 12 пункты 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "ташламалардан файдаланучылар саны һәм ташламаларны куллану өчен потенциаль хокукка ия булган түләүчеләр саны һәм бирелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы 5 еллык чорда.»

2.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының (mamadysh.tatarstan.ru) рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге
башкарма комитеты рәисе /Р.Г.Шәйхетдинов/